РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

СОВЕТ
НИЖНЕШИТЦИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422067, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Нижние Шитцы, ул. Тукая, 15
тел. (84362) 46-4-42

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН ШЫТСУ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

422067, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Түбән Шытсу авылы, Тукай урамы, 15 йорт
тел. (84362) 46-4-42

e-mail: shic.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
23.10.2024

КАРАР
№ 22

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советының 2021 елның 08 нче ноябрендә 23 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Һава кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 08.08.2024 ел, №289-ФЗ Федераль закон нигезендә Саба муниципаль районының Түбән Шытсу авыл җирлеге Советы

Карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге Советының «Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 08.11.2021 ел № 23 карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6.3. Планнан тыш күчмә тикшерү «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 31.07.2020 №248 - ФЗ Федераль законның 1 өлешендәге 3-6 пунктлары, 57 статьясындагы 3 өлеше һәм 66 статьясындагы 12 һәм 12.1 өлешләре нигезендә прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин.»;

1.2. 4.9.4 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.9.4. Урынга барып тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең 4.2.1 пунктының 2 пунктчасында каралган карар кабул ителергә тиеш түгел».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Түбән Шытсу авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shitsi адреслары буенча рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

Түбән Шытсу авыл җирлеге башлыгы Б.М.Мәүлетов